РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» сентябрь 2020 ел г. Альметьевск № 1351

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 7 сентябрендәге 1341 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 16 апрелендәге 294 номерлы, «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 31 маендагы 412 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 21 маендагы 413 номерлы карарлары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 7 сентябрендәге 1341 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 14 июнендәге 1149 номерлы, 2020 елның 17 мартындагы 357 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтада:

1.1.1. 1 бүлекнең 1.2 пунктындагы өченче һәм дүртенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«төп оклад - календарь ай өчен һөнәри квалификация төркеме йә хезмәт нормасы (хезмәт хакы ставкасы өчен атнага (елга) педагогик эш нормасы) нигезендә компенсацияләрне, стимуллаштыручы һәм социаль түләүләрне исәпкә алмыйча һөнәри эшчәнлекне гамәлгә ашыручы муниципаль учреждение хезмәткәренең хезмәт хакы ставкасы;

вазыйфаи оклад - компенсация, кызыксындыру һәм социаль түләүләрне исәпкә алмыйча, календарь ай өчен (фактта эшләнгән вакытны исәпкә алып)

хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәү өчен хезмәткәрнең хезмәтенә түләүнең билгеләнгән күләме;»;

1.1.2. 7 бүлектә:

а) 7.1 пунктының бишенче абзацында «сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 7.7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.7. Тәрбияләнүчеләрнең (укучыларның) аерым категорияләре белән эшләгән өчен компенсация характерындагы түләүләр мәгариф хезмәткәрләренә аерым мәгариф оешмаларында бирелә.»;

7.7.1 пунктының беренче, дүртенче, унберенче абзацларында «сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

7.7.2 пунктының беренче абзацында «сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

15 нче таблица исемендә «сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.1.3. Нигезләмәгә 1 нче кушымтада:

«Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалар Союзы, Россия федератив Социалистик Республикасы ведомство (тармак) бүләкләре» бүлегендәге 2 пунктны түбәндәге эчтәлекле 2.6 пункт белән тулыландырырга:

| | |
|---|---|
| «2.6. | «Мәгариф отличнигы» билгесе; |

1.2. 2 нче кушымтада:

1.2.1. 1 бүлекнең 1.2 пунктындагы өченче һәм дүртенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«төп оклад - календарь ай өчен һөнәри квалификация төркеме йә хезмәт нормасы (хезмәт хакы ставкасы өчен атнага (елга) педагогик эш нормасы) нигезендә компенсацияләрне, стимуллаштыручы һәм социаль түләүләрне исәпкә алмыйча һөнәри эшчәнлекне гамәлгә ашыручы муниципаль учреждение хезмәткәренең хезмәт хакы ставкасы;

вазыйфаи оклад - компенсация, кызыксындыру һәм социаль түләүләрне исәпкә алмыйча, календарь ай өчен (фактта эшләнгән вакытны исәпкә алып) хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәү өчен хезмәткәрнең хезмәтенә түләүнең билгеләнгән күләме;»;

1.2.2. 3 бүлекнең 3.2 пунктында «беренче - икенче төркем белән» сүзләрен «бер - ике төркем белән» сүзләренә алмаштырырга;

1.2.3. 5 бүлекнең 5.6 пунктына түбәндәге эчтәлекле уникенче абзац өстәргә:

«Педагогика хезмәткәрләре һәм мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында 2020 елның 1 гыйнварына кадәр ике айдан өч яшькә кадәрге балалар өчен ике яшь төркемнәрендә, өч яшьтән алып җиде яшькә кадәрге балалар өчен өч яшь төркемнәрендә хезмәт күрсәткән структур бүлекчәләр җитәкчеләренә педагогик хезмәткәрләргә һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләренә хезмәт күрсәтү, хезмәтнең ешлыгы өчен түләүләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында» 2019 елның 02 июлендәге 546 номерлы карары үз көченә кергән көнгә түләнә торган күләмдә башкарыла.»;

1.2.4. Нигезләмәгә 1 нче кушымтада:

«Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалар Союзы, Россия федератив Социалистик Республикасы ведом-

ство (тармак) бүлəклəре» бүлегенең 2 пунктына түбəндəге эчтəлекле 2.6 пунктча өстəргə:

| | |
|---|---|
| «2.6. | «Мəгариф отличнигы» билгесе; |

1.3. 3 нче кушымтада:

1.3.1. 1 бүлекнең 1.2 пунктындагы өченче һəм дүртенче абзацларын түбəндəге редакциядə бəян итəргə:

«төп оклад - календарь ай өчен һөнəри квалификация төркеме йə хезмəт нормасы (хезмəт хакы ставкасы өчен атнага (елга) педагогик эш нормасы) нигезендə компенсациялəрне, стимуллаштыручы һəм социаль түлəүлəрне исəпкə алмыйча һөнəри эшчəнлекне гамəлгə ашыручы муниципаль учреждение хезмəткəренең хезмəт хакы ставкасы;

вазыйфаи оклад - компенсация, кызыксындыру һəм социаль түлəүлəрне исəпкə алмыйча, календарь ай өчен (фактта эшлəнгəн вакытны исəпкə алып) хезмəт (вазыйфаи) бурычларын үтəү өчен хезмəткəрнең хезмəтенə түлəүнең билгелəнгəн күлəме;»;

1.3.2. 8 бүлекнең 8.9 пунктында:

икенче абзацта «җитəкче урынбасарларына» сүзлəреннəн соң «, баш бухгалтерга» сүзлəрен өстəргə;

өченче, алтынчы, җиденче, унынчы, унберенче абзацларда «җитəкче урынбасарларына» сүзлəреннəн соң «, баш бухгалтерга» сүзлəрен өстəргə;

1.3.3. Нигезлəмəгə 1 нче кушымтада:

«Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Совет Социалистик Республикалар Союзы, Россия федератив Социалистик Республикасы ведомство (тармак) бүлəклəре» бүлегенə түбəндəге эчтəлекле 2.7 пунктча өстəргə:

| | |
|---|---|
| «2.7. | «Мəгариф отличнигы» билгесе; |

1.4. 4 нче кушымтада:

1.4.1. 1 бүлекнең 1.2 пунктындагы өченче һəм дүртенче абзацларын түбəндəге редакциядə бəян итəргə:

«төп оклад (база вазыйфаи оклад), хезмəт хакының база ставкасы – минималь оклад (вазыйфаи оклад), тиешле һөнəри квалификация төркеменə керүче эшче яки җитəкче, белгеч, техник башкаручы һөнəре буенча, компенсация, стимуллаштыручы һəм социаль түлəүлəрне исəпкə алмыйча һөнəри эшчəнлекне гамəлгə ашыручы Əлмəт муниципаль районы мəгариф оешмалары хезмəткəрлəренең төп эш хакы ставкасы;

вазыйфаи оклад - компенсация, кызыксындыру һəм социаль түлəүлəрне исəпкə алмыйча, календарь ай өчен (фактта эшлəнгəн вакытны исəпкə алып) хезмəт (вазыйфаи) бурычларын үтəү өчен хезмəткəрнең хезмəтенə түлəүнең беркетелгəн күлəме;».

2. Əлеге карар, аңа кагылышлы түбəндəге үзгəрешлəрдəн тыш, рəсми басылып чыкканнан соң үз көченə керə дип билгелəргə:

гамəлдə булуы 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгəн хокук мөнəсəбəтлəренə кагыла торган Əлмəт муниципаль районының өстəмə белем бирү мəгариф оешмалары хезмəткəрлəренə хезмəт өчен түлəү шартлары турында нигезлəмəнең 8 бүлегенең 1.3.2 пунктында;

Əлмəт муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары хезмəткəрлəренə хезмəт өчен түлəү шартлары турында нигезлəмəнең 7 бүлегенең 1.1.2 пунктында; Əлмəт муниципаль районы гомуми белем бирү

оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә 1 нче кушымтаның 1.1.3 пунктында; Әлмәт муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәнең 3 бүлегенең 1.2.2, 5 бүлегенең 1.2.3 пунктларында; Әлмәт муниципаль районының мәктәпкәчә мәгариф оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә 1 нче кушымтаның 1.2.4 пунктында; гамәлдә булуы 2020 елның 22 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла торган Әлмәт муниципаль районының өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы нигезләмәгә 1 нче кушымтаның 1.3.3 пунктында.

3. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Н. Подоваловка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов